ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МУСАБАЙ-ЗАВОД» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

«25» май 2020 ел **№ 53/1**

«Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 декабрендәге «2020 елга,2021 һәм 2022 еллар планы чорына Мусабай-Завод авыл җирлегенен бюджеты турында» 50/3 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм «Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 декабрендәге «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планы чорына Мусабай-Завод авыл җирлегенең бюджеты турында» 50/3 санлы карарына үзгәрешләр һәм остәмәләр кертү хакында» мәгълүматны тыңлап, муниципаль берәмлек Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 декабрендәге «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планы чорына Мусабай-Завод авыл җирлегенец бюджеты турында» 50/3 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 маддә 1 пункт 1 пунктчада «8853,65» саннарын «9418,92» саннарына алыштырырга,

- 1 маддә 1 пункт 2 пунктчада «8853,65» саннарын «9495,48» саннарына алыштырырга,

- 1 маддә 1 пункт 3 пунктчада «0» саннарын «76,56» саннарына алыштырырга.

2. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советының 2019 елның 06 декабрендәге «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планы чорына Мусабай-Завод авыл җирлегенец бюджеты турында» 50/3 санлы карарының 1, 3, 7, 9, 11 кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар халыкка рәсми игълан ителгәниәи соң, законлы көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Ф. Ә. Әгъләҗева